**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы**
**Иске Карамалы авыл җирлегенә керүче Яңа Карамалы авылы**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№1** **16.11.2023 ел**

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Иске Карамалы авыл җирлегенә керүче
Яңа Карамалы авылында узган
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2022 елның 16 нчы ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Сез, 2023 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегенең Яңа Карамалы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларына, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 750 (җиде йөз илле) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә, Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт төзегән гражданнарны, һәм шулай ул хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә» һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлап тоту:
- Яңа Карамалы авылы эчендәге юлларны кышкы көне карап тору, Бакча урамы;
Яңа Карамалы авылы эчендәге юлларны җәй көне карап тору, Бакча урамы;
Бакча урамын хезмәтләр өчен килешүе буенча грейдирлау.
Яңа Карамалы авылы күперен ремонтлау;
- юл буендагы үләннәрне чабу;
2) Зияратны карап тоту, төзекләндерү:
Яңа Карамалы авылы зиратының коймасын буяу;
Яңа Карамалы авылы зиратыннан каты коммуналь калдыкларны туплау һәм ташу эшчәнлеген оештыру;
Яңа Карамалы авылы зиратлары территориясендә үлән чабу;
3) Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны оештыру;
- Яңа Карамалы авылы халкын эчәр су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклау зонасын оештыру;
су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, аварияләрне бетерү, электр энергиясе өчен түләү;
4) халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:
- Сабантуй паркында эскәмияләр ясау;
халыкның күпләп ял итү территорияләрендә үлән чабу;
5) - урам яктыртуга хезмәт күрсәтү, яктырткычлар сатып алу;
6) беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:
- гидрант җайланмалары кую.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 98 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 51.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
Гражданнар җыенында катнашкан 51 кеше «РИЗА» позициясе өчен,
0 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:
1.Татарстан Республикасы Мөслим унициpаль районы Иске Карамалы авыл җирлегенең Яңа Карамалы торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. 2023 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегенең Яңа Карамалы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә, 1 һәм 2 төркем инвалидларына, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 750 (җиде йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертергә.
3. Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт төзегән гражданнарны, хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә.
4. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлап тоту:
- Яңа Карамалы авылы эчендәге юлларны кышкы көне карап тору, Бакча урамы;
Яңа Карамалы авылы эчендәге юлларны җәй көне карап тору, Бакча урамы;
Бакча урамын хезмәтләр өчен килешүе буенча грейдирлау.
Яңа Карамалы авылы күперен ремонтлау;
- юл буендагы үләннәрне чабу;
2) Зияратны карап тоту, төзекләндерү:
Яңа Карамалы авылы зиратының коймасын буяу;
Яңа Карамалы авылы зиратыннан каты коммуналь калдыкларны туплау һәм ташу эшчәнлеген оештыру;
Яңа Карамалы авылы зиратлары территориясендә үлән чабу;
3) Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны оештыру;
- Яңа Карамалы авылы халкын эчәр су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклау зонасын оештыру;
су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, аварияләрне бетерү, электр энергиясе өчен түләү;
4) халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:
- Сабантуй паркында эскәмияләр ясау;
халыкның күпләп ял итү территорияләрендә үлән чабу;
5) - урам яктыртуга хезмәт күрсәтү, яктырткычлар сатып алу;
6) беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:
- гидрант җайланмалары кую.

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Иске Карамалы авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Карамалы авыл җирлеге башлыгы И.Н.Кәримов